РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
ЧЕРКИ-ГРИШИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮЛ ЧЕРКЕНЕ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«06» февраль 2023 ел № 1-67

Физик затлар мөлкәтенә салым турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә ярашлы рәвештә, Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салымны мәҗбүри түләүгә кертергә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын түбәндәге зурлыкта билгеләргә:

1) 0,1 процент нисбәтендә:

Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 бүлегендә күрсәтелгән, шул исәптән салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннарына;

мәйданнары 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше өчен бирелгән җир участокларында урнашкан хуҗалык корылмаларына карата;

2) 0,2 процент нисбәтендә:

фатир;

бүлмә;

3) 0,3 процент нисбәтендә:

торак йортлар;

тәмамланмаган төзелеш объектлары, мондый объектларның проектлаштырыла торган билгеләнеше торак йорт булса;

составына ким дигәндә бер торак йорт керә торган бердәм күчемсез комплекслар;

4) 2 процент нисбәтендә:

Россия Федерациясе Салым кодексының 378_2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына;

Россия Федерациясе Салым кодексының 378_2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектлары, шулай ук кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата;

5) Салым салуның башка объектларына карата 0,5 процент;

Физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән түбәндәгеләрне азат итәргә:

3.1. 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар.

3.2. Әлеге пунктның 3.1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнар балаларын мөлкәткә салым түләүдән азат итәргә.

Салым ташламасы күп балалы гаиләгә туры килә торган салым салуның бер объектына карата салым түләүче сайлау буенча бирелә. Салым ташламасы Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче салым түләүчеләргә салым түләүче милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган салым салу объектына карата салым түләүче тарафыннан салым суммасы түләнергә тиеш күләмдә бирелә.

Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелергә мөмкин:

1) фатир, фатир өлеше яисә бүлмә;

2) торак йорт яисә торак йорт өлеше.

3.3. Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Күл Черкене_ авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган (алга таба-хәрби хезмәткәрләр) Россия Федерациясе гражданнарын һәм аларның гаилә әгъзаларын мөлкәт салымыннан азат итәргә.

Хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзалары дигәндә түбәндәгеләр аңлашыла:

1) хәрби хезмәткәрләр белән никахта торучы ир яисә хатын;

2) 18 яшькә җитмәгән яки аннан өлкәнрәк булган, әгәр алар 18 яшькә җиткәнче инвалид булсалар, шулай ук белем бирү оешмаларында көндезге уку формасы буенча укучы, уку тәмамланганчы, әмма алар 23 яшькә җиткәнче хәрби хезмәткәр балалары;

3) хәрби хезмәткәрнең әти-әнисе.

Салым ташламасы Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә урнашкан һәр төрдәге салым салу объектына карата салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына карамастан, салым түләүчене сайлау буенча бирелә.

Салым ташламасы Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче салым түләүчеләргә салым түләүче милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган салым салу объектына карата салым түләүче тарафыннан салым суммасы түләнергә тиеш күләмдә бирелә.

4. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Күл Черкене авыл җирлеге Советының 2022 елның 30 декабрендәге 2-64 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарын көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карар 3.3 пунктчасы нигезләмәсенең гамәлдә булуы. 2021-2022 еллардагы салым чорында физик затлар милкенә салымны исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Совет рәисе,
ТР Буа муниципаль районы Күл Черкене
авыл җирлеге башлыгы М.К. Истиев